

Жир шарында яшәvче халыкнын бер-берсе белән аралашуын тәэмин итvче бу хезмәт, интернет челтәре чолгап алган заманда да, актуальлеген югалт-мый. Кешеләр аны бvген дә яздырып ала. Почта, хатлар аша ерак араларны якынайтып, хис-кичерешләрне житкерv, вакытлы матбугат басмаларын тарату очен кирәк. Шуна кvрә хат ташучыны һәр йортта диярлек котеп алалар. Әмма бvген бу профессия турында кечкенәдән ук хыялланмый әлеге яшьләр. Сәбәпләре бар. Ә кирәклелеге беренчеләр рәтендә. Кvбрәк авыл жирендә.      Бvген кvпме генә интернет турында сойләсәләр дә, кәгазьгә язган хатны алу - vзе бер рәхәтлек. Олылар аларны саклый да әле.  Ә газеталар...
Кочкурово районы Татар Ымызы авылында Хажирә Абдулла кызы Абдуллова менә шундый котеп алынучы һонәр ияләренен берсе. Утыз дvрт ел гомерен почта хезмәтенә багышлаган Хажирә Абдулла кызы.
-  Почтада 1965 елнын декабрендә эшли башладым, - ди Х.А.Абдулова. - Профессиямне сайлауга берничә сәбәп этәрде: газета, журналларны һәм хатларны туган авылыма ташу балаларым белән бергә булырга момкинчелек бирде. Почта бvлеге ул вакытта кvрше Качелай авылынын Профессиональное училище урамында урнашкан иде. Шуннан почтаны Татар Умызына тимер юл буйлап жәяvләп барып ала идем. Прессадан башка, телеграммнар ташыдым. Ул вакыт кәрәзле телефоннар юк иде, стационары да сирәк йортта булды. Кочкурово телеграфыннан тонлә дә шалтырата торган иделәр һәм шул ук вакытта халыкка житкерәсе бар бит. Житкерә идем. Халыкнын пенсиясен дә ташыдым. Шул вакыт Ымызда лаеклы ялда 320 кеше иде. Пенсия акчасы йортvгә аеруча игътибарлы булырга кирәк. Һәм мине беркем дә рәнжетмәде...
Прессаны халык кvп укыды. Авылыбызга газета-журналлар, хатлар, бәйрәмгә кvп кенә открыткалар елдан-ел арта барды. Юкка гына хат ташучылар турында шигырь дә чыгармаганнардыр: «Кто стучится в дверь ко мне с толстой сумкой на ремне?» Шулай, хат ташучыларнын сумкалары калын һәм авыр булды элекке заманнарда.
- Эшем чынлап та авыр иде, - дип сvзен дәвам итә Абдулла кызы Хажирә. - Авылыбыз газета-журналларны кvп иттереп яздырып алдылар. Бер минутка гына кvз алдыгызга китерегез: 200 экземпляр район газетасы «Заря», 153 - «Сельская жизнь», тагы «Азат хатын», «Ялкын» журналлары, «Гудок», «Правда», «Труд», «Аргументы и факты», «Молодой ленинец», «Учительская газета», «Пионерская правда»… Ә атна буе китермәгән очракта, арба белән китерә иделәр. Шул тау кадәр кәгазьгә карап: ничек

әле боларны тапшырасы булыр, дип уйга кала идем. Ә кознен пычрагында, янгырда, бигърәк буранда авыр булды. Шоферлардан авылга кадәр житкерvне сорала торган идем инде сонга. Башта авылнын бер ягына тапшырып чыга идем, аннары сумкамны янадан тутырып икенче урамга эләштем. Эләшеп олгермәсәм - балаларым булышты. Афганистан жирендә сугыш барган чакларда, халык Хажирә Абдулла кызы Абдуллованы куркып каршы алган вакытлар да анын исендә. Әйе, тыныч тормыш вакытында солдат әниләре уллары турында похоронка алсыннарчы!
- Бvгенге тосле исемдә, Ымызыбыз егетенә похоронка килде. Ничекләр генә тапшырасы булыр?! Кич киттем, тәвәккәлләп. Тиз генә әйтә дә алмадым әнисенә ойләренә килгәч. Башта хәлләрен сораштым, хужалыгындагы эшләрне барладым. Кайгылы хәбәремне сонга гына әйтә алдым, дип хәтерен янарта Хажирә апа Абдулова.
Бик тә тырышып хат ташучы булып эшләгән Хажирә Абдулла кызы Абдулова. Кушканны жиренә житкереп башкаручы хезмәткәр мактауга лаек. Пенсиягә чыккан чакта да тагы эш-ләргә соралганнар vзеннән. «За достижение высоких показателей в повышении эффективности и качества работы, досрочное выполнение заданий и социалистических обязательств...» дигән язулар белән ул «Ударник одиннадцатой пятилетки» ботенсоюз билгесе белән бvләкләнгән.
- Кеше, олыгая барган саен, кvбрәк vткән тормышына әйләнеп кайта. Йок-ларга ятканда еш кына башкарган эшләрем турында уйлыйм, - дип сvзен йомгаклый Хажирә Абдулла кызы, - ничегрәк шундый авыр эшне башкардым икән?! Шул вакыт авыр сумкалар ташыдым, балалар тәрбияләдем, хужалыкны да алып бардым бит - бар жирдә дә олгердем!
Якташларыма теләгем шул: Яна елда һәрвакыт шатлыклы хәбәрләр генә алып килсеннәр сезгә!

**Наилә Насырова**